**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423747, Киров авылы,
Киров урамы, 39 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**СОВЕТ КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 39.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**КАРАР**
**17 .09.2019**

**Решение**
**№ 25**

## Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Киров авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми санынннан 30 процентган да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Атомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру;
- Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;

**“ӘЙЕ “** **“ЮК”**

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Киров авылы, Киров ур.,39 йорт, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыр.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Актаныш муниципаль районы
Киров авыл җирлеге Советы Рәисе И.Ф.Гаянов